ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 777 4 сентября 2018 г.

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 12 маенда кабул ителгән «Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегендә субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтүдә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибе турында» 319нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең Бюджет Кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 18 июлендә кабул ителгән 178-ФЗ номерлы Федераль Закон һәм Федераль Законның «Россия Федерациясенең Бюджет Кодексына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең закон чыгару акларының аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану турында» 3нче маддәсенә нигезләнеп, карар чыгарам:

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 12 маенда кабул ителгән «Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегендә субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтүдә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибе турында» 319нчы номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Вәкаләтле оешма, Вәкаләтле орган, дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан, субсидия алучының аны бирү тәртибен, шартларын, максатларын үтәвен тикшереп торуына ризалык бирүе» сүзләрен «субсидия алучылар һәм китерүче булган затлар (подрядчиклар, башкаручылар) арасында бюджет чараларын төп таратучының (таратучы) субсидияләр бирүдә үз йөкләмәләрен үтәве максатыннан төзелгән килешүләр буенча, һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан субсидия алучының аны бирү тәртибен, шартларын, максатларын үтәвен, алынган чаралар хисабына куелган тыюларны үтәвен тикшереп торуы, югары технологияле чит ил җиһазларын, чимал, комплектлаучы эшләнмәләрне сатып алуда (китерүдә) Россия Федерациясенең валюта турында законы нигезендә чит ил валютасын кулланып, шулай ук күрсәтелгән чараларны тәкъдим итү максатына ирешүгә бәйле башка операцияләрдә, дәүләт (муниципаль оешма булмаган) коммерцияле булмаган оешмаларга субсидия бирүне тәэмин итүче норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актларга таянып, ризалык бирүе)» сүзләре белән алыштырырга.

Житәкче А.Г. Сәйфетдинов